ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

17.09.2018                 с. Верхний Услон                 1052

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
территориясендә җайга салынулы
тарифлар буенча пассажирларны һәм багажны
автомобиль транспорты белән даими ташучы
муниципаль маршрутлар билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунына, “Россия Федерациясендә пассажирларны һәм багажны автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым канун актларына үзгәрешләр кертү турында” 13.07.2015 №220-ФЗ Федераль канунына һәм “Россия Федерациясендә пассажирларны һәм багажны автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым канун актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль канунны тормышка ашыру турында” 26.12.2015 №107-ЗРТ Татарстан Республикасы Канунына туры китереп, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 60 км. озынлыктагы «Канаш ав. – Югары Ослан с.» №1 җайга салынулы тарифлар буенча даими ташучы муниципаль маршрутын билгеләргә.

1.1. «Канаш ав.– Югары Ослан с.» маршруты буенча башлангыч һәм соңгы пунктларны билгеләргә:

- “Канаш ав.” башлангыч тукталыш пункты тукталыш павильоны- Центральная урамы, Канаш авыл җирлеге административ бинасы янында;

- “Югары Ослан с.” соңгы тукталыш пункты – Чехов урамы, ГБУ «Югары Ослан РГВО» янындагы мәйдан .

2. «Канаш ав.– Югары Ослан с.» маршруты буенча аралык маршрутлары:

Олы Мәми саласына борылыш - Мәйдан саласына борылыш – Егидерево авылына борылыш - Рус Макылы авылы – Татар Макылы авылы –Куралово саласына борылыш – Никольский поселогына борылыш– Түбән Ослан с. һәм Югары Ослан с. чатлыгы (авылга кермичә).

1.3 «Канаш ав.– Югары Ослан с.» маршруты буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чараларының хәрәкәт итүе көтелгән автомобиль юлларының исемнәре: Канаш ав. -Р241 керү юлы «Казан – Буа - Ульяновск»- Югары Осланга керү юлы.

1.4. Даими ташу маршрутының озынлыгы : 60 км.

1.5. Пассажирларны утырту һәм төшерү тәртибе: билгеләнгән тукталыш пунктларында гына.

1.6. Даими ташулар төре: даими тарифлар буенча даими пассажир ташулары.

1.7. Транспорт чараларының төрләре һәм классы: техник биремгә туры китереп.

1.8. Транспорт чараларының экологик характеристикалары - техник биремгә туры китереп.

1.9. Планлаштырылган расписание – көн саен.

2. 37 км. озынлыктагы « Шылангы саласы – Югары Ослан с.» №2 җайга салынулы тарифлар буенча даими ташучы муниципаль маршрутын билгеләргә.

2.1 « Шылангы саласы – Югары Ослан с.» маршруты буенча башлангыч һәм соңгы пунктларны билгеләргә:

- «Шылангы саласы» башлангыч тукталыш пункты - Шылангы саласы, Сайдашев урамына борылыш;

- “Югары Ослан с.” соңгы тукталыш пункты – Чехов урамы, ГБУ «Югары Ослан РГВО» янындагы мәйдан .

2.2 «Шылангы саласы – Югары Ослан с.» маршруты буенча аралык маршрутлары: Шылангы саласы (Школьная урамына борылыш);
- Яңа Юл посёлогына борылыш - Мулланур Вахитов исемендәге авыл – Матюшино авылына борылыш - Никольский посёлогына борылыш – Түбән Ослан с. һәм Югары Ослан с. чатлыгы (авылга кермичә).

2.3 «Шылангы саласы – Югары Ослан с.» маршруты буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чараларының хәрәкәт итүе көтелгән автомобиль юлларының исемнәре: «Казан-Ульяновск» - Кама Тамагы – Р241 «Казан-Буа-Ульяновск» - Югары Осланга керү юлы.

2.4 . Даими ташу маршрутының озынлыгы : 37 км.

2.5. Пассажирларны утырту һәм төшерү тәртибе: билгеләнгән тукталыш пунктларында гына.

2.6. Даими ташулар төре: даими тарифлар буенча даими пассажир ташулары.

2.7. Транспорт чараларының төрләре һәм классы: техник биремгә туры китереп.

2.8. Транспорт чараларының экологик характеристикалары - техник биремгә туры китереп.

2.9. Планлаштырылган расписание – көн саен.

3. 25 км. озынлыктагы «Иннополис ш. – Югары Ослон с.» №3 җайга салынулы тарифлар буенча даими ташучы муниципаль маршрутын билгеләргә.

3.1 « Иннополис ш. – Югары Ослан с.» маршруты буенча башлангыч һәм соңгы пунктларны билгеләргә:

- «Иннополис ш.» башлангыч тукталыш пункты – Иннополис ш., Университетская урамы,1;

- “Югары Ослан с.” соңгы тукталыш пункты – Чехов урамы, ГБУ «Югары Ослан РГВО» янындагы мәйдан .

3.2 «Иннополис ш. – Югары Ослан с.» маршруты буенча аралык маршрутлары: Урман Морквашы саласы – Түбән Ослан с. һәм Югары Ослан с. чатлыгы (авылга кермичә).

3.3 . Даими ташу маршрутының озынлыгы : 25 км.

3.4. Пассажирларны утырту һәм төшерү тәртибе: билгеләнгән тукталыш пунктларында гына.

3.5. Даими ташулар төре: даими тарифлар буенча даими пассажир ташулары.

3.6. Транспорт чараларының төрләре һәм классы: техник биремгә туры китереп.

3.7. Транспорт чараларының экологик характеристикалары - техник биремгә туры китереп.

3.8. Планлаштырылган расписание – көн саен.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисадый үсеш буенча Башкарма комитет урынбасарына тапшырырга.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **Л.С. Хакимзянов**

Әзерләде һәм җибәрде
О.А.Сельская